**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 гыйнвар № 37

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру өчен торак төзүчеләрне, җир кишәрлекләрен, торак төзелеше проектларын сайлап алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 14 июль, 496 нчы карары белән расланган «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру өчен торак төзүчеләрне, җир кишәрлекләрен, торак төзелеше проектларын сайлап алу тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру өчен торак төзүчеләрне, җир кишәрлекләрен, торак төзелеше проектларын сайлап алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 ел, 14 июль, 496 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 27 апрель, 290 нчы, 2015 ел, 12 сентябрь, 669 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру өчен җир кишәрлекләрен, торак төзүчеләрне, торак төзелеше проектларын сайлап алу тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымтада:

II бүлектә:

3 пунктта «(2014 ел бәяләрендә)» сүзләрен «(агымдагы ел бәяләрендә)» сүзләренә алмаштырырга;

III бүлектә:

2.1 пунктның 3 пунктчасында, 2.2 пунктның 3 пунктчасында, 2.3 пунктның 3,4 пунктчаларында «2014 ел» сүзләрен «агымдагы ел» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтада:

5 – 7 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «5. | Сайлап алу датасына кадәр узган соңгы ике елда торакны кулланылышка кертүнең җыелма күләме, мең кв. метр (КС-11 формасы буенча) | |
| 6. | Төзүченең 2017 елның 31 декабренә кадәр экономик класстагы торакның гомуми мәйданы кимендә 10 мең кв. метр тәшкил итә торган торак төзелеше объектларын кулланылышка кертү йөкләмәсе булу (бар/юк) | |
| 7. | Төзүченең «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру өчен федераль законнар нигезендә билгеләнгән экономик класстагы торакның иң югары бәясеннән артмаган бәя белән экономик класстагы торакны сату буенча йөкләмәсе булу (бар/юк)». | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\37.docx